ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Мәдәният турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның тугызынчы абзацында «мәдәният өлкәсендә эстетик тәрбия, сәнгать белеме бирү һәм педагогик эшчәнлек» сүзләрен «эстетик тәрбия, сәнгать белеме бирү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«эстетик тәрбия һәм сәнгать белеме алуга, мәгариф турындагы законнар нигезендә эстетик тәрбия һәм сәнгать белеме алу рәвешләрен сайлауга;»;

3) $10^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$10^1$ статья. **Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларына карата Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары бурычлары**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) (алга таба – мәдәни мирас объектлары) саклап калуны, алардан файдалануны, аларны популярлаштыруны һәм дәүләт саклавын тәэмин итәләр.»;

4) 13 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр оешмаларына мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен әзерләүдә катнашу мөмкинлеген тәэмин итә, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү, эш белән тәэмин итү, хезмәт шартлары буенча чаралар эшләүдә алар белән киңәшеп эш итә, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, аларның эшчәнлегенә тыкшынмый.»;

5) 15 статьяда түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

6) 16 статьяда:

а) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

7) 17 статьяда:

а) бишенче һәм сигезенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«инвалидларга дәүләт музейларыннан, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән (исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган федераль дәүләт музейларыннан һәм исемлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы раслый торган федераль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән тыш) файдалана алу шартларын тәэмин итү;

Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

8) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. **Мәдәният өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Татарстан Республикасында җирлекләрнең, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары мәдәният өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне федераль законнар нигезендә башкаралар.»;

9) 19 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәдәният өлкәсендә милекчелек объектларын сатып алу тәртибе, аларга хуҗа булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү шартлары Россия Федерациясе законнары белән регламентлаштырыла.»;

10) 21 статьяның бишенче өлешендәге икенче җөмләне төшереп калдырырга;

11) 28 статьяда түбәндәге эчтәлекле алтынчы өлеш өстәргә:

«Керемнәренең бердәнбер чыганагы авторлык түләве булган иҗади берлекләр һәм ассоциацияләр әгъзалары, шулай ук иҗади берлекләр әгъзалары булмаган башка иҗади хезмәткәрләр, Россия Федерациясе Пенсия фондына иминият кертемнәре түләгән очракта, иминият пенсиясенә хокуклы.»;

12) 31 статьяның өченче абзацында «саклау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон, 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 статьяның 7 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 5 декабре
№ 101-ТРЗ